Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка Р.Г. Ниязова шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2022 елның 18 октябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Р.Г. Ниязова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый

нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең конституциячел законнар бүлеге мөдире Л.И. Ибраһимова, Татарстан Республикасы Конституция суды инициативасы буенча суд утырышына чакырылган белгечләр — Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты юридик бүлеге башлыгы урынбасары Е.В. Кожевникова, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты бюджет башкарылышы бүлеге башлыгы Л.В. Вәлиева аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы урынбасары И.А. Гомзик, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсенең административ хокук һәм законнарны системалаштыру бүлекчәсе мөдире К.А. Кознова, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы С.А. Трошин, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.А. Зорькина, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы Е.Ю. Степанова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм

башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Г. Ниязова «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы юридик зат хокукына ия, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән һәм үз исеме язылган мөһере, шулай ук тиешле бюджет счетлары һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган башка счетлары бар.

Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасына түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте (алга таба — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты);

2) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика агентлыклары, хезмәтләре, инспекцияләре, үзәкләре, палаталары, департаментлары, комитетлары, баш идарәләре, идарәләре, комиссияләре һәм башка органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары);

4) Татарстан Республикасы вәкиллекләре.

Татарстан Республикасы Законының 30 статьясы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты юридик зат булып торуын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган Нигезләмә нигезендә эш итүен; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратын тоту чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын тоту чыгымнары чикләрендә гамәлгә ашырылуын (3 һәм 4 пунктлар) күздә тота.

Татарстан Республикасы Законының китерелгән нигезләмәләренә таянып, гражданка Р.Г. Ниязова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты кебек үк, юридик зат хокукларына ия дип саный.

Мөрәҗәгатьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, Татарстан Республикасы Югары суды билгеләмәсе белән мөрәҗәгать итүче файдасына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан 15 300 сум күләмендә суд чыгымнарын түләтү билгеләнгән. Әлеге суд акты нигезендә гражданка Р.Г. Ниязова Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына тапшырган үтәтү кәгазе бирелгән. Шул ук вакытта үтәтү кәгазе, үтәлмичә, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган, чөнки бурычлының күрсәтелгән Департаментта һәм аның территориаль бүлекләрендә ачылган шәхси счетлары юк.

Гражданка Р.Г. Ниязова фикеренчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының шәхси счетлары булмау әлеге оешманың юридик зат буларак теркәлмәвенә бәйле. Мөрәҗәгать итүче санаганча, бу үзе шикаять белдерә торган Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре хокук куллану практикасында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма һәм күрсәтмә бирү органы буларак, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юридик зат итеп теркәлмәгән булырга мөмкинлек биргән дәрәҗәдә әлеге нормаларның

Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә билгесезлек тудыра. Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрен куллануның мондый практикасы, гражданка Р.Г. Ниязова фикеренчә, суд карарын үтәүгә аның конституциячел хокукын гамәлгә ашыруга каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 18, 19, 24 (беренче һәм икенче өлешләр), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 40 (беренче өлеш), 41, 60, 103 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасында хосусый, дәүләти, муниципаль милек һәм милекнең башка рәвешләре бертигез дәрәҗәдә таныла һәм яклана; җир һәм башка табигать ресурслары хосусый, дәүләти, муниципаль милектә һәм милекнең башка рәвешләрендә булырга мөмкин; милек кагылгысыз; законлы рәвештә булдырган мөлкәтне биләгәндә, аннан файдаланганда, аның белән эш иткәндә милекченең хокукларын чикләү, федераль законда каралган очраклардан гайре, рөхсәт ителми; милек дәүләт һәм җәмгать мәнфәгатьләренә, кеше хокукларына, ирекләренә һәм абруена каршы кулланылмаска тиеш; милек объектларын ирексезләп тартып алу, федераль законда билгеләнгән очраклардан гайре, рөхсәт ителми; Татарстан Республикасы Конституциясе — республиканың Төп законы, Татарстан Республикасының хокукый системасында иң югары юридик көчкә ия, турыдан-туры гамәлдә була һәм Татарстан Республикасының барлык территориясендә кулланыла; Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының хокукый актлары Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килмәскә тиеш; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмгать берләшмәләре,

оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; Татарстан Республикасында һәркемгә аның хокукларын һәм ирекләрен, намусын һәм абруен, гомерен, сәламәтлеген һәм мөлкәтен суд тарафыннан яклау тәэмин ителә; дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, вазыйфаи затларның, шулай ук җәмәгать берләшмәләренең карарларына һәм гамәлләренә (яисә гамәл кылмавына) карата судка шикаять бирелергә мөмкин; Татарстан Республикасында һәркем Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясе Конституциясен һәм федераль законнарны үтәргә тиеш; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара һәм аларның үтәлешен тикшерә; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә

мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре аларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының да һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының да хокукый нигезләмәсен билгеләүче җайга салу аңа, хокук куллану практикасы бирә торган мәгънәсеннән чыгып, гражданның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәтү хокукын гамәлгә ашыруга каршы килгән һәм шуның белән аның суд яклавына хокукын чикләгән дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нормалар дәүләт хакимияте органнары системасын оештыру мәсьәләләренә карый. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «н» пункты) нигезендә дәүләт хакимияте органнары системасын оештыруның гомуми принципларын билгеләү Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагына керә. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләре). Шул ук вакытта дәүләт хакимияте органнары системасы Россия Федерациясенең конституциячел төзелеш нигезләре һәм дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнарын оештыруның федераль законда билгеләнгән гомуми принциплары нигезендә Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан

мөстәкыйль билгеләнә (Россия Федерациясе Конституциясенең 77 статьясы, 1 өлеш).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон преамбуласының беренче абзацы нигезендә (алга таба шулай ук — 184-ФЗ номерлы Федераль закон) Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары системасы алар тарафыннан Россия Федерациясенең конституциячел корылышы нигезләре һәм әлеге Федераль закон нигезендә мөстәкыйль билгеләнә.

184-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 3 өлеше нигезендә (2022 елның 1 июненә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы исеме, аның структурасы, аны формалаштыру тәртибе Россия Федерациясе субъектының тарихи, милли һәм башка традицияләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе субъекты Конституциясе (уставы) һәм законнары белән билгеләнә.

Шуның белән, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән Россия Федерациясе һәм аның субъектлары карамагындагы мәсьәләләрне бүлешүдән чыгып эш иткән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 13 пункты нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, аның нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары системасын билгеләү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына керә.

3. 184-ФЗ номерлы Федераль законның (2022 елның 1 июненә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) 17 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектында Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары

башкарма органы җитәкчелегендә башкарма хакимият органнары системасы билгеләнә (1 пункт); Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы Россия Федерациясе субъекты конституциясе (уставы) нигезендә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе) тарафыннан билгеләнә (4 пункт).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары системасын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары тәшкил итә (өченче өлеш).

Күрсәтелгән хокукый җайга салуның дәвамы буларак, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә бәйле хокук мөнәсәбәтләрен регламентлаштыру максатларында карала торган Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән. Шулай, әлеге Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган 8 статьясы белән республика закон чыгаручысы Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасына түбәндәгеләр керә дип билгеләгән:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

2) Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика агентлыклары, хезмәтләре, инспекцияләре, үзәкләре, палаталары, департаментлары, комитетлары, баш идарәләре, идарәләре, комиссияләре һәм башка органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары);

4) Татарстан Республикасы вәкиллекләре.

Китерелгән норма үзенең хокукый мәгънәсе буенча Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә охшаш, аларны конкретлаштыруга һәм закон акты дәрәҗәсендә структуралаштыруга

юнәлдерелгән, һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми.

Югарыда аталган системага керүче башкарма хакимият органнары статусы Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган 6 статьясы белән билгеләнә, аның нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы юридик зат хокукына ия, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән һәм үз исеме язылган мөһере, шулай ук тиешле бюджет счетлары һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган башка счетлары бар (1 пункт).

Күрсәтелгән норманың хокукый эчтәлеге 184-ФЗ номерлы Федераль законның (2022 елның 1 июненә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) 20 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләреннән турыдан-туры килеп чыккан, алар нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы юридик зат хокукларына ия, герблы мөһере бар. Шуның белән бергә «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә бүгенге көндә әлеге норма үз көчен югалткан дип танылуын да билгеләп үтәргә кирәк. Әмма бу Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте башкарма органының юридик зат хокукларын һәм герблы мөһере булу мөмкинлеген кире какмый.

Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының 3 пунктчасының һәм 10 статьясындагы 3 пунктының нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — үзенең ведомство территориясе чикләрендә үз карамагындагы мәсьәләләр буенча дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы, үзенә буйсынган тармак, тармакара һәм махсус компетенциядәге башкарма хакимият органнарын берләштерүче һәм аларның эшчәнлегенә юнәлеш бирүче башкарма хакимиятнең гомуми компетенциядәге даими эшләүче коллегиаль органы.

Карала торган Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пункты нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә күрсәтелгән нормаларның

эчтәлегеннән һәм хокукый мәгънәсеннән күренгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — юридик зат хокукларына ия булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма һәм күрсәтмә бирү органы. Аталган башкарма хакимият органының юридик зат хокуклары булу аның оештыру һәм функциональ бәйсезлеге гарантияләренең берсе булып тора, чөнки гамәлдәге законнар нигезендә мондый статус аңа йөкләнгән функцияләрне аннан башка нәтиҗәле гамәлгә ашырып булмый торган мәҗбүри шарт булып тора. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең төп эшчәнлеген гомумдәүләт, региональ мәсьәләләрне хәл итү өчен гавами хокук кысаларында гамәлгә ашыра һәм шул максатларда гражданлык мөнәсәбәтләре әйләнешенә керә, бу аның хокукый сәләтенең катлаулы составтагы характеры турында сөйли. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук Россия Федерациясе Граждан кодексының 124 һәм 125 статьялары белән үзара бәйләнешендә әлеге кодексның 2 статьясындагы 1 пунктының 2 абзацындагы нигезләмәләргә дә туры килә, алар нигезендә Россия Федерациясе субъектлары, дәүләт хакимияте органнары исеменнән, граждан законнары белән җайга салынучы мөнәсәбәтләрдә шул мөнәсәбәтләрдәге башка катнашучылар — гражданнар һәм юридик затлар белән бер үк нигезләрдә эш йөртәләр; шул ук вакытта аларга, әгәр законнан яисә бу субъектларның үзенчәлегеннән башкасы килеп чыкмаса, граждан законнары белән җайга салынучы мөнәсәбәтләрдә юридик затларның катнашуын билгели торган нормалар кулланыла.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе мәгънәсе буенча (34 статья, 1 өлеш) бер үк зат дәүләт идарәсе өлкәсендәге хакимият эшчәнлеген һәм системалы табыш алуга юнәлдерелгән эшмәкәрлек эшчәнлеген берләштерә алмый; федераль закон чыгаручы дәүләт хакимияте дәрәҗәләре арасында вәкаләтләрне бүлешеп кенә калмый, ә тиешле вәкаләтләргә карата Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының субъектлык хокуклары үзенчәлекләрен дә билгели, алар хакимияткә буйсынуга нигезләнгән мөнәсәбәтләрдә дәүләт

атрибутикасына ия булучы хакимият ияләре сыйфатында булалар, ә граждан-хокукый мөнәсәбәтләрдә бу мөнәсәбәтләрнең башка катнашучылары белән бертигез булалар; шул ук вакытта, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары граждан-хокукый мөнәсәбәтләрдә махсус хокукый сәләте булган субъектлар буларак катнашалар, ул аларның гавами-хокукый табигате нигезендә граждан хокукының башка субъектларының — гражданнарның һәм юридик затларның хокукый сәләтенә туры килми (1998 елның 1 октябрендәге 168-О номерлы; 2006 елның 2 ноябрендәге 540-О номерлы билгеләмәләр).

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты махсус хокукый сәләткә ия, ул үзенең гавами-хокукый табигате нигезендә граждан хокукының башка субъектлары — гражданнарның һәм юридик затларның шәхси мәнфәгатьләрне күздә тоткан хокукый сәләте белән туры килми дигән нәтиҗәгә килә. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан куелган мәсьәләгә карата бу федераль һәм республика законнары нигезендә юридик зат хокукларына ия булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәү узарга тиеш түгел дигәнне аңлата.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының китерелгән эш режимы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген тәэмин итү һәм ул кабул иткән карарларның башкарма хакимият органнары тарафыннан башкарылуын тикшереп торуны оештыру максатларында төзелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының төзелүен алдан билгеләгән, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын тоту чыгымнары чикләрендә Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган 30 статьясындагы 4 пункты нигезендә финанслана һәм Татарстан Республикасы Законының шушы ук статьясының дәгъвалана торган 3 пункты нигезендә аңа юридик зат статусы бирелгән. Карала торган Татарстан Республикасы Законының аталган статьясы белән

аларның үзара бәйләнешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турындагы нигезләмә нормаларының эчтәлегеннән күренгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм финанс ягыннан тәэмин итү мәсьәләләре аның Аппараты тарафыннан тәэмин ителә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының китерелгән вәкаләтләре характеры аның граждан законнары белән җайга салынулы мөнәсәбәтләрдә катнашуы үзенчәлекләренә тәэсир итә, шулай ук юридик зат буларак граждан-хокукый хокукый сәләткә ия булу һәм теркәлү кирәклегенә бәйле.

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында үз файдасына чыгарылган суд актын үтәтеп булмау турындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк дип саный.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, суд яклавына хокукын тулы күләмдә тормышка ашырырга һәм тигезлек, гаделлек таләпләренә җавап бирүче гадел хөкем аша хокукларны нәтиҗәле торгызуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче гарантияләр булуны күздә тота; шул исәптән дәүләт органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны да кертеп, шул ук вакытта теләсә нинди хокук бозуларны бетерүнең кирәкле хокукый механизмнарын булдырып, дәүләт хокукларны һәм ирекләрне танырга, үтәргә һәм якларга тиеш (2011 елның 22 апрелендәге 5-П номерлы, 2012 елның 27 декабрендәге 34-П номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге 8-П номерлы, 2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы һ.б. карарлар).

«Россия Федерациясендә суд системасы турында» 1996 елның 31 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел законның 6 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләре буенча федераль судларның, җәмәгать судьяларының һәм Россия Федерациясе субъектлары судларының

законлы көченә кергән карарлары, шулай ук аларның законлы күрсәтмәләре, таләпләре, йөкләмәләре, чакырулары һәм башка мөрәҗәгатьләре дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, җәмәгать берләшмәләренең, вазыйфаи затларның, башка физик һәм юридик затларның берниндиә дә искәрмәсез барысы өчен дә мәҗбүри булып тора һәм Россия Федерациясенең бөтен территориясендә тайпылышсыз үтәлергә тиеш.

Китерелгән җайга салу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 декабрендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты регламентының (алга таба шулай ук — Регламент) 106 статьясындагы икенче абзацы нигезләмәләрендә үз чагылышын тапкан, алар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына куелган таләпләр суд тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта, тиешле башкарма хакимият органы билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карар турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кичекмәстән хәбәр итә, суд карарына карата шикаять бирү турында тәкъдимнәр кертә, ә суд карары үз көченә кергәч — аны үтәү чаралары турында белдерә.

Шуның белән бергә, хокук куллану практикасында дәгъва белдерелә торган нормаларның нигезләмәләрен бюджет законнары нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә аңлату, шул исәптән Р.Г. Ниязова эше буенча хокук куллану карарларыннан күренгәнчә, юридик зат буларак теркәлү булмау һәм, нәтиҗәдә, аның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында шәхси счеты булмау сәбәпле, фактта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актларын үтәүнең мөмкин булмавына китерә. Шул ук вакытта, юридик зат статусы һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында тиешле тәртиптә ачылган шәхси счетлар булуга карамастан, аңа үтәтү кәгазе тапшыру да мөмкин түгел, чөнки бер ягы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты булган суд эшләрендә аның үзе урынына Аппаратын танырга ярамый, чөнки Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасында дәүләт башкарма хакимиятенең гәүдәләнеше булып тора.

Күрсәтелгәннәр гражданны суд карарын үтәтү тәртибен үзгәртү турындагы таләп белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә. Күрсәтелгән хокук конституциячел гарантия булып торганда, мондый таләп суд яклавына хокукны иллюзор характерда итә, Россия Федерациясе Конституциясенең 46 статьясында (1 өлеш) беркетелгәнчә, һәр кеше, кирәк булганда, суд яклавына хокукыннан тулы күләмдә файдалана алсын өчен дәүләт кирәкле шартлар тудырырга тиеш.

Суд карарын үтәүнең мәҗбүри булуы нигезле рәвештә шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: гавами хакимият органын юридик зат буларак теркәүнең булмавы үзе үк гражданның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәтү хокукын гамәлгә ашыруга каршы килмәскә һәм шуның белән суд яклавына хокукка каршы төшмәскә тиеш. Киресенчә, федераль законнарның һәм Регламентның югарыда китерелгән нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм (яки) башкарма хакимиятнең алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән органы тиешле суд карарын үтәү буенча үзенә бәйле барлык чараларны күрергә тиеш, шул чакта шәхес, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрен үзара килештерү нигезендә гражданга бирелә торган акчаны тиешле срокта алу өчен реаль мөмкинлек тудырылыр иде.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2021 елның 26 апрелендәге 284 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан күчемсез мөлкәт объектларының кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен дәгъвалау турында административ эшләр буенча суд чыгымнарын түләтү турындагы суд актларында булган таләпләрне үтәү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы итеп билгеләгән. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан

Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары эшчәнлеген (төп функцияләрен) хокукый җайга салуда мондый якын килү Регламентның 106 статьясы күрсәтмәләре белән туры килер иде, суд карарларын үтәүнең мәҗбүрилеге турында югарыда күрсәтелгән Федераль конституциячел закон нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлешен тулысынча тәэмин итәр иде, шулай ук суд яклавының тулылыгы, нәтиҗәлелеге һәм үз вакытында башкарылуы конституциячел әһәмиятле максатларына ирешүгә ярдәм итәр иде дип саный.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре үзләре үк Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый халәтен билгеләүгә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына юридик зат статусын беркетүгә юнәлдерелгән. Шул ук вакытта, гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы үз эчтәлегеннән, хокукый мәгънәсеннән һәм урыныннан чыгып, күрсәтелгән закон нигезләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәүгә гражданның хокукын гамәлгә ашыруга йогынты ясамый, чөнки дәүләт хакимияте органы тарафыннан мондый суд карарын үтәү мәҗбүрилеге аны юридик зат буларак теркәүгә бәйле түгел. Димәк, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституциясенә, шул исәптән аның 28 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 40 (беренче өлеш) статьяларына туры килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына,

66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының, 8 статьясындагы 1 пунктының, 30 статьясындагы 3 һәм 4 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга, чөнки алар үзеннән-үзе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый халәтен билгеләүгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына юридик зат статусын беркетүгә юнәлдерелгән һәм аны юридик зат буларак теркәү фактына карамастан гражданның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан суд чыгымнарын түләтү турында суд актын үтәтү хокукын гамәлгә ашыруга каршы килмиләр, димәк, гражданның суд яклавына хокукын чикләмиләр.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 108-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**